**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 елның 29 июле** **№ 46**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Уставына үзгәрешләр**
**һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелүгә бәйле рәвештә Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 7 статьяда:

а) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу»;

б) 15 пунктта «шул исәптән сатып алу юлы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 19.3 пункт өстәргә:

«19.3) район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;

г) түбәндәге эчтәлекле 35 пункт өстәргә:

«35) «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау».

2. Әлеге карарны «Идел таңнары» газетасында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**

**муниципаль район Советы рәисе** **П.Н. Лоханов**